# Кытайда яшәүче татар диаспорасы теленең кайбер лингвистик үзенчәлекләре

*Нәбиуллина Г.Ә. Фатхуллова К.С.*
*Казан (Идел буе) федераль университеты*

*Мәкалә РГНФ 11-04-00074а номерлы грант кысаларында язылды*

В статье представлен тематический анализ китайских заимствованных слов, составляющих специфический пласт лексики татарской диаспоры, проживающей в КНР. Объектом исследования являются китайские лексические заимствования, бытующие в разговорном дискурсе.

Тюрколог галимнәр төрки телләрнең кытай теле белән бәйләнешенә бик күптәннән игътибар итеп килгәннәр (Васильев, 1872; Баскаков, 1951). Мәгълүм ки, борынгы төрки телдә кулланылган кытай алынмалары төрки сүзлекләрдә теркәлеп калган (ДТС, 1969; Ligeti, 1966; Clausin, 1972; Gabain, 1974). Төрле этимологик сүзлекләрдә урын алган килеп чыгышы кытай теленә нисбәтле аерым лексик берәмлекләргә бәйле сылтамалар төрки телләрдә кытай алынмаларының шактый күп булуын күрсәтә. Борынгы төрки халыклар, төрки телләр тарихы буенча язылган фәнни хезмәтләрдә кытай алынмалары турында гомум характердагы күзәтүләр билгеле. Төрки телләрдә урын алган кытай алынмалары хакында В.Радлов, К.Юдахин, Н.Баскаков, Д.Насилов, Jarring һ.б. галимнәрнең фәнни тикшеренүләре мәгълүм (Радлов, 1897, 1899; Малов, 1951, 1952; Бернштам, 1940, 1946; Jarring, 1936 ). Сүз уңаеннан кытайлар белән янәшә яшәгән уйгырлар телендә урын алган кытай алынмалары турында язылган махсус монографик хезмәтләр, тәрҗемә характерындагы аңлатмалы сүзлекләр булуын да әйтеп узарга кирәк [Новгородский 1951; Рахимов 1970]. Бу хезмәтләрдә алынма берәмлекләрнең килеп чыгышын, тарихын өйрәнеп язылган шактый зур тел материалы бирелә. Танылган галим Н.А.Баскаков фикеренчә, кытай алынмалары мәсьәләсе фәнни нигездә чагыштырмача аз өйрәнелгән. Галим һәр конкрет телнең лексик составында кытай алынмалары күпләп кулланылу

мөмкинлеген күрсәтә, шуның белән бергә бу проблема тюркологлар тарафыннан җитди рәвештә өйрәнелергә тиешлеген дә искәртә [Баскаков 1987].

Фәнни тикшеренүләребезнең төп максаты - Кытайда яшәүче татар диаспорасы сөйләменең үзенчәлекле бер катламын тәшкил иткән кытай алынмаларын барлау, тематик яктан төркемләп тикшерү. Әлеге диаспора телендә киң чагылыш тапкан кытай алынмалары тикшеренү объекты итеп алынды. Бер яктан, татар телендә кытай алынмаларының кулланылышы моңа кадәр тикшерелмәгән булуы, икенче яктан, Кытай Халык Республикасында яшәүче татарларның сөйләм теле үзенчәлекләре монографик планда өйрәнелмәгән булуы бу юнәлештәге фәнни тикшеренүләрнең әһәмиятен ассызыклый.

Кытай Халык республикасында төрки халыклар, күпләп, аерым алганда, казахлар, уйгырлар, үзбәкләр, һәм дә татарлар яшиләр. Татарларны Кытайда ике төрле атап йөртәләр - «татарлар» һәм «дадань». Алар Кытайда яшәүче һәм ислам динен тотучы ун милләтнең берсен тәшкил итәләр. Тарихчы галим М.Госманов сүзләренә караганда, “Кытайдагы татарлар ике зур төркемнән гыйбарәт: дәүләтнең көнчыгыш-төньяк территориясе булган Манчжуриядә яшәгәннәре һәм илнең көнбатыш өлкәләрен тәшкил итүче Шәркый Төркестан яки Уйгырстан җирләрендә төпләнеп гомер кичергәннәре. Тамырлары бер булса да, оешу һәм яшәү шартлары, язмышлары аларның төрлечә” [Госманов 1996: 4].

Татарларның күп өлеше Синьцзян, Чанцзи-хуэйск автономияле округында, Или һәм Чэн районнарында яшиләр. 2000 нче елгы статистик мәгълүматларга караганда, Синьцзянда 5 меңгә якын татар исәпләнә. Шулай ук Пекинда, Тяньцзин, Харбин, Чжэнчжоу һәм башка зур шәһәрләрдә татарлар яшәве билгеле. Татарлар күпләп яшәгән зур шәһәрләрдән Голҗа, Урумчи, Чавучак шәһәрләре санала. Бүгенге көндә Кытайда яшәүче татарлар күбрәк фән, хезмәт белән мәшгуль. Бу төбәктәге татарларның хәзер мәктәпләре дә, бернинди оешмалары да юк. Уйгыр, казахлар кебек татарлар

күбрәк кытай телендә белем алалар, кытай телендә сөйләшәләр һәм аралашалар. Татарлар уйгыр һәм казахлар белән катнашып яшиләр, шунлыктан алар уйгыр һәм казах язуын кулланалар. Бу хакта галим М. Госмановның “Ябылмаган китап яки чәчелгән орлыклар” (1996), М.Ерзинның “Тропою предков” (2005) дигән китапларыннан бай мәгълүмат табарга мөмкин.

Татарларның Кытайга күчеп килүләре турында тарихи хезмәтләрдә төрле фикерләр яшәп килә. Ышанычлы тарихи чыганакларга караганда, татарларның бу илгә күчеп килүләрен  ике этапка бүлеп карыйлар: XIX гасырның беренче елларында һәм икенче Бөтендөнья сугышыннан соң. Кытайның кайбер тарихи чыганакларында исә бирегә күчеп килгән татарларны Тан чорына ук бәйләп карыйлар.

Татарларның Кытайга күпләп күченеп килүләре 1890 нчы еллар ахырында Кытай көнчыгыш тимер юлын төзегән чорга туры килә. Алар юл төзелешендә актив катнашалар, сәүдә эшләре белән шөгыльләнгәннәр. Нәтиҗәдә,  Кытайның төньягында  татар җәмгыяте барлыкка килә.

Кытайда яшәүче татарларның географик урнашуы, иҗтимагый-сәяси тормышы, көнкүреше, мәдәнияте һәм күрше дәүләтләр, кытайлар белән үзара мөнәсәбәтләре, әлбәттә, аларның сөйләмендә һәм телендә чагылыш тапмый калмаган. Тыгыз территориаль бәйләнеш, сәүдә, мәдәни багланышлар – болар барысы да Кытайда яшәүче татарлар теленә кытай алынмалары үтеп керү өчен, реаль шартлар булып торганнар. Югарыда билгеләп үтелгәнчә, кытай алынмалары татар диаспорасы теленә иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни бәйләнешләр нәтиҗәсендә килеп кергәннәр.

Татар диаспорасы сөйләмендә кулланылган алынмалар, нигездә, иҗтимагый-сәяси, мәгариф, фән, хәрби өлкәләргә карыйлар. Кытайдагы икътисад, мәдәният һәм фән үсеше, иҗтимагый-сәяси тормыш, матур әдәбият һәм массакүләм мәгълүмат чаралары, кытай алынмалары үтеп керү өчен, җирлек булып торганнар. Т.Р. Рахимов үзенең фәнни хезмәтендә билгеләп үткәнчә, «... китайские заимствования охватывали в основном

административно-управленческую, торговую, бытовую терминологию и в очень небольшой степени сельскохозяйственную, ремесленную и военную лексику» [Рахимов 1970: 3].

Тупланган материаллардан күренгәнчә, кытай алынмалары дәүләт төзелеше, иҗтимагый-сәяси тормышка, мәгариф өлкәсенә, кытай халкының гореф-гадәтләренә, тормыш-көнкүрешкә бәйле лексик берәмлекләрне-реалияләрне белдереп киләләр.

Беренче зур төркемне иҗтимагый-сәяси реалияләрне белдерә торган алынма берәмлекләр тәшкил итәләр. Бу төркемгә түбәндәге лексик-семантик берәмлекләр хас.

1. Хакимият оешмаларын, җитәкчелек итүне белдергән алынма берәмлекләр: *党中央 - данчжунъян (партия),党委 - данвэй (партия комитеты), 中共 - чжунгун (Кытай компартиясе), 厅长 - тинчжан (назир, департамент башлыгы);*

2. Иҗтимагый-сәяси эшчәнлекне белдерә торган алынмалар:

а) сәяси эшчәнлек һәм эшлеклеләр: *总统 - цзунтун (президент), 部长 - бучжан (министр),总理 - цзунли (премьер-министр), 首长 - чжужэнъ (башлык);*

б) дәрәҗә, титуллар, мөрәҗәгать сүзләре*: 所长 - сочжан (директор), 副院长- фуюаньчжан (суд рәисе урынбасары), 局长 - цзюйчжан (бюро башлыгы), 队长 - дуйчжан (отряд башлыгы), 主席 - чжуси (рәис),副书记 - фушуцзи (сәркатип урныбасары), 厂长 - чанчжан (завод директоры), 处长- чучжан (бүлек башлыгы),专家 - чжуанъцзя (белгеч), 教授 - цзяошоу (профессор), 副教授 - фуцзяошоу (доцент);*

в) милли күренешләр һәм милли хәрәкәтләр (аларның вәкилләре): *汉族 - ханъцзу (Кытай милләте), 华侨 - хуацяо (Кытай эмигранты), 藏族 - цзанцзу (тибетлы);*

д) оешма атамалары*: 派出所 - пайчусо (милиция бүлеге), 检察院- цзянъчаюан (прокуратура),传真 - чуанъчжэнь (факс), 海关 - хайгуань (таможня);*

е) уку йортлары һәм мәдәни оешмалар: *科学院 - кэсюэюанъ (фәннәр академиясе), 剧院 - цзюйюанъ (театр),大学 - дасюэ (университет), 京剧 - цзинцзюй (театр, пьеса, драма).*

3. Хәрби реалияләрне белдергән алынма берәмлекләр. Бу төркем үз эчендә түбәндәге төркемчәләргә бүленә: а) хәрби бүлекчә атамалары: *兵团- бинтуань (дивизия),指挥部 - чжихуйбу (команда штабы), 解放军 - цзефан цзюнь (азат итү армиясе), 军区 - цзюньцюй (хәрби округ)*; б) коралл атамалары:*军舰 - цзюнь цзянь (хәрби кораб), 活塞 - хосай (поршень),火箭- хоцзянь (ракета);* в) хәрби хезмәткәрләр: *团长- туаньчжан (полковник),班长- баньчжан (бүлек командиры), 将军-цзянцзюнь (генерал).*

Икенче зур тематик төркемне көнкүреш лексикасы тәшкил итә. Бу төркемгә ашамлык, кием-салым һәм тормыш-көнкүрешкә караган башка этнографик реалияләр керә.

1. Азык-төлек һәм эчемлек атамалары: *豆腐 - доуфу (бакча борчагы сыры), 馍馍 - момо (парда пешерелгән икмәк), 麻花 - махуаэр (майда кыздырылган койрык),菜 - цай (салат),油塔子 - ютацзы (парда пешерелгән катламлы икмәк); 凉粉 - лянфэнъ (желе сыман салкын ашамлык),挂面 - гуамянъ (токмач), 粉条子 - фэньтяоцзы (крахмалдан, бәрәңге, борчак оныннан әзерләнгән токмач), 米饭 - мифанъ (дөгедән әзерләнгән ризык), 酱 - цзян (соус, паста), 饺子 - цзяоцзи (пилмән), 糖棕子- танцзунцзы (дөгедән пешерелгән өчпочмак формасындагы пәрәмәч, шикәр белән бирелә), 酱油 - цзянъю (соя соусы),筷子- куайцзы (ашаганда, чәнечке урынына кулланыла торган таякчыклар),案板 - анъбанъ (кухня тактасы).* Алынмаларның күбесе яшелчә, җиләк-җимеш һәм башка үсемлек атамаларын белдерәләр:

*青菜- цинцай (яшелләкләр), 韭菜- цзюцай (исле суган), 葱 - цун (лук), 萝卜 - лобу (шалкан), 茄子 - цецзы ( баклажан), 香蕉 - сянцзяло (банан), 菠菜 - боцай (шпинат).*

2. Кием-салым атамалары: *旗袍 - ципао (күтәргән якалы хатын-кыз күлмәге), 裁缝 - цайфэн (тегүче).*

3. Башка предмет атамалары: *桌子 - чжоцзы (өстәл),菜园子- цайюаньцзы (бакча), 板凳 - баньдэн (такта),铡刀 - чжадао (зур пычак), 变压器 - бяньяци (трансформатор).*

Этнографик реалияләр арасында кытайларның гореф-гадәте, йола-бәйрәмнәренә караган алынма сүзләр дә очрый. Мәсәлән, *秧歌 - янгэр (Кытайда дөге күчереп утыртканда, шулай ук Яңа ел бәйрәмнәрендә җырлана торган җыр), 三九三 - саньцзюсань (кышның зәмһәрир суыгы).*

Эш-хәрәкәтне белдергән алынмалар да очрый: *干杯- ганьбэй (бокалдагы эчемлекне эчеп бетерү )*. Шунысын искәртеп узарга кирәк: югарыда билгеләп үтелгән кытай алынмалары татар телендә генә түгел, Себердә, Урта Азиядә, Көнчыгыш Европада кулланыла торган төрки телләрдә дә очрыйлар.

Татар теленә кытай алынмалары үтеп керү, үзләштерелү процессы төрле чорларга бәйле. Хронологик яктан татар дисапорасы телендә урын алган кытай алынмалары үткән һәм хәзерге чорларга карый. Кайберләре исә бик борынгыдан кулланылып, телнең актив сүзлек составын тәшкил итәләр: *桌子 - чжоцзы (өстәл), 葱 - цун (суган), 油塔子 - ютацзы (парда пешерелгән катламлы икмәк) һ.б.* Хәзерге телдә мондый кытай сүзләре алынма буларак кабул ителми. Безнең карашка, татар теленә кытай алынмаларының үтеп керү процессы бигрәк тә XX гасырның 50 нче елларында – Кытайда тел сәясәте хакимлек иткән вакытларда активлаша. Шунысын искәртеп узу мөһим: кытай алынмалары билгеле бер дәрәҗәдә кытай теленең фонетик һәм грамматик закончалыкларына буйсынып кабул ителгәннәр. Кытай һәм татар телләрендә тәңгәл фонемалар булган алынмалар җиңелрәк

үзләштерелгәннәр, татар телендә тәңгәллеге булмаган кытай фонемалары исә охшаш авазлар белән үзгәртелгән. Бигрәк тә сузык авазлар системасында фонетик нормалар үзгәрешләргә дучар була. Мәсәлән, татар телендә төшерелмә *эй, ий, аэ* дифтонглары кулланылмый.

Хәзерге татар диаспорасы телендә урын алган кытай алынмалары, сан ягыннан караганда, лексиканың зур булмаган бер өлешен тәшкил итәләр. Кытай халкы белән "тел, лөгать алмашып" яшәгән шартларда актив кулланылыштагы кытай алынмаларының саны татарларның сөйләмендә арта баруы гаҗәп түгел. Кытай алынмаларының кулланылышы киңәю, иң беренче чиратта, тормыш ихтыяҗы белән аңлатыла ала.

Кытай алынмаларына лингвистик анализ ясау аларның үсеш-үзгәрешен, мәгънәләре тараю яисә киңәю хасиятләрен, кулланылыш сәбәпләрен, характерын һәм татар диаспорасы теленең сүзлек составы үзгәрү процессында ролен билгеләргә ярдәм итә. Шул рәвешле, кытай алынмалары татар диаспорасы телендә киң таралганнар һәм сүзлек составын лексик-семантик яктан баетуда әһәмиятле роль уйнаганнар. Кытай алынмаларын алга таба киң планда җентекләп өйрәнү татар һәм кытай халыкларының тел-мәдәни бәйләнешләре мәсьәләләрен, ике телнең үзара тәэсирен җентекләп тикшерүдә нигез булып тора.

Әдәбият


1. Баскаков Н.А., Насилов В.М. Уйгурско-русский словарь. – Москва, 1939.
2. Баскаков Н.А**.** К проблеме китайских заимствований в тюркских языках // Turcica et Orientalia. Studies in honour of Gunnar Jarring on his eightieth birthday. - Istanbul, 1987.
3. Госманов М. Ябылмаган китап яки чәчелгән орлыклар. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1996. – 206 б.
4. Лотте Д.С. Вопросы заимствования и упорядочения иноязычных терминов и терминоэлементов. – М., 1982.
5. Национальные меньшинства в Китае. // Восточный свет. - №1. - 2008. - С. 66-76.
6. Новгородский В.И. Китайские элементы в уйгурском языке. – Москва, 1951.
7. Рахимов Т. Р. Китайские элементы в современном уйгурском языке. - Москва, 1970.